Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының өченче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

26 октябрь, 2020 ел № 16

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе контрактының гамәлдә булу срогы чыгу сәбәпле һәм Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына затны билгеләү турында карар кабул иткән өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының вәкаләтләре срогы бетүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2018 елның 14 сентябрендәге 159 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә конкурс үткәрергә.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документларны 2020 елның 28 октябреннән 16 ноябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч ав., 18 йорт, 20 кабинет, 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр һәм 13.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, 3-10-12 телефоны.

Конкурсны 2020 елның 19 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Питрәч муниципаль районы Советы бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч ав., Совет ур., 18 йорт.

4. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау буенча конкурс комиссиясе составының яртысын өч кеше составында расларга.

5. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау буенча конкурс комиссиясе составының икенче яртысы «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2014 елның 22 декабрендәге ПУ - 1164 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән билгеләнгән дип игътибарга алырга.

6. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында «Вперед» («Алга») газетасында хәбәр урнаштырырга.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов

Кушымта
Питрәч муниципаль районы
Советы карары белән расланды
26 октябрь, 2020 года № 16

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Вәлиуллин<br>Руслан Рөстәмович | - комиссия рәисе, Питрәч муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе; |
| Галеев<br>Илдус Йосыфович | - комиссия рәисе урынбасары, Питрәч муниципаль районы Советы депутаты, «Макс-Ойл» ҖЧҖ генераль директоры |
| Арсентьева<br>Альбина Александровна | - комиссия секретаре, Питрәч муниципаль районы Советының оештыру эшләре бүлеге башлыгы |